ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИШЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

2024 ел, 2 декабрь №94

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге башлыгының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Ишеево авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 гыйнварындагы 52 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлегенең башлыгы һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «18260» санын «19173» санына алмаштырырга;

1.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «а)елга 12,86 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итүче норматив чикләрендә 20547 сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү;»;

2.2 пунктта «13323» санын «13990» санына алмаштырырга.

2.Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Ишеево авыл җирлеге башлыгы,
Ишеево авыл җирлеге Советы рәисе Р.Р. Сатдинов